КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«23» 06. 2026 г. № 106-п

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгы белән расланган Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгы белән расланган Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә (“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 27 мартындагы 56-п номерлы, 2025 елның 2 июнендәге 65-п номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр:

журналист – теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе өчен хәбәрләрне һәм материалларны редакцияләү, төзү, җыю яисә әзерләү белән шөгыльләнүче, редакциягә хезмәт мөнәсәбәтләре яисә башка шартнамәчел мөнәсәбәтләр белән бәйле йә редакция йөкләмәсе буенча шундый эшчәнлек белән шөгыльләнүче физик зат;

журналистлар коллективы – уртак иҗади хезмәт белән конкурс эшен булдырган һәм конкурс эше призлы урын алган очракта акчаларны процент нисбәтендә бүлү турында килешү тапшырган ике һәм аннан күбрәк, иң күбе биш, журналист;

автор – иҗади хезмәте белән конкурс эшен булдырган граждан;

авторлар коллективы – уртак уй-фикер һәм план буенча конкурс эшен булдыру өчен берләшкән, конкурс эше призлы урын алган очракта акчаларны процент нисбәтендә бүлү турында Оештыручыга килешү тапшырган иң күбе биш кешедән торган төркем.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Социаль челтәрләрдә урнаштыру өчен наркотикларга каршы һәм/яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы видеоролик» (1, 2, 3 урын).

«Социаль челтәрләр өчен наркотикларга каршы иң яхшы мем һәм /яисә график сурәтләр (рәсемнәр) сериясе» (1, 2, 3 урын).

«Сәламәт яшәү рәвеше турында иң яхшы текст/ шигырь/җыр»(1,2,3 урын).

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинация (1, 2, 3 урын).

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Конкурска гариза бирүчеләр – әлеге Нигезләмәнең 5.2. пункты нигезендә гариза тапшырган журналистлар, журналистлар коллективы, авторлар, авторлар коллективлары (алга таба – гариза бирүчеләр).»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Конкурста катнашу 14 яшькә җиткән эшкә сәләтле физик затларга рөхсәт ителә.»;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Конкурста катнашу гариза бирүчеләрнең алга таба эшләрне Оештыручы тарафыннан түләүсез, ләкин журналистын, журналистлар коллективын, авторын, авторлар коллективын, шулай ук алынган чыганагын күрсәтеп, файдалануга (мәгълүмати, фәнни, белем бирү һәм мәдәни максатларда) ризалык бирүен аңлата.»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Гариза түбәндәге документлар теркәлеп тапшырыла:

а) конкурс эшләре – наркотикларга каршы юнәлештәге һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы видеороликлар, наркотикларга каршы юнәлештәге һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мемнар яисә рәсемнәр сериясе,

сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы текст, шигырь, җыр. Өстәмә рәвештә иллюстрацияләр, дизайн-макетлар, видео һ.б. тапшырылырга мөмкин.

Видеоролик жанры катнашучы тарафыннан мөстәкыйль сайлана (интервью, репортаж, видеоклип, мультфильм һ.б.).

Конкурска тапшырылган видеороликларның вакыты 2 минуттан артырга тиеш түгел.

Конкурска тапшырылган мемнар һәм рәсемнәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

саны: бер сериядә кимендә 3 һәм иң күбе 10 мем/рәсем;

форматы: JPEG, PNG, GIF, кимендә 800 х 600 пиксель;

һәрбер мем/рәсем буенча аңлатма булырга тиеш (100 сүзгә кадәр).

Конкурска тапшырылган шигырь, җыр тексты түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

шигырь: күләме – иң күбе 2 басма бит (Times New Roman шрифты, 14 кегль).

Барлык текстлы эшләргә рәсем, иллюстрация, инфографика кушып бирелергә мөмкин.

б) әлеге Нигезләмәгән 1 нче кушымта нигезендә конкурста катнашу өчен анкета;

в) персональ белешмәләрне эшкәртүгә законнарда каралган таләпләрне үз эченә алган ризалык (гариза журналистлар коллективы яисә авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта, журналистлар коллективының яисә авторлар коллективының барлык әгъзалары тарафыннан да бирелә);

г) персональ белешмәләр субъекты тарату өчен рөхсәт иткән персональ белешмәләрне эшкәртүгә законнарда каралган таләпләрне үз эченә алган ризалык (гариза журналистлар коллективы яисә авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта, журналистлар коллективының яисә авторлар коллективының барлык әгъзалары тарафыннан да бирелә);

д) гариза журналист тарафыннан бирелгән очракта – редакция таныклыгы яисә журналистның вәкаләтләрен раслый торган башка документ (гариза журналистлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта редакция таныклыгы яисә журналист шәхесен йә журналистлар коллективының барлык әгъзаларын раслаучы башка документлар тапшырыла);

е) шәхесне раслаучы документ – гариза автор тарафыннан бирелгән очракта (гариза авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта авторлар коллективының барлык әгъзаларының шәхесен раслаучы документлар тапшырыла);

ж) персональ белешмәләрне эшкәртүгә 14 яшькә җиткән балигъ булмаган затның ата-анасының (законлы вәкиленең) ризалыгы белән рәсмиләштерелгән һәм законда каралган таләпләргә туры килә торган ризалыгы (әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаган зат булса);

з) персональ белешмәләр субъекты тарату өчен рөхсәт иткән персональ белешмәләрне эшкәртүгә 14 яшькә җиткән балигъ булмаган затның ата-анасының (законлы вәкиленең) ризалыгы белән рәсмиләштерелгән һәм законда каралган таләпләргә туры килә торган ризалыгы (әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаган зат булса);

и) конкурс эше призлы урын алса акчаларны процент нисбәтендә бүлү турында килешү (гариза журналистлар коллективы яисә авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта тапшырыла);

к) конкурс эше Россия Федерациясе составына керә торган республикаларның дәүләт телендә, Россия халыклары телләрендә тапшырылса – эшнең русчага тәрҗемәсе бирелә (татар теленнән тыш).

Әлеге пунктның «б» - «к» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, кәгазь документларның электрон сурәтләре рәвешендә, ачык форматта, гамәлдәге программалар белән тәэмин ителгән җайланмалар аша тулысынча яки аерым өлешләрен карау мөмкинлеге булган килеш Конкурс үткәрү турында чыккан хәбәрдә күрсәтелгән электрон почта адресына «Россия патриоты» тамгасы белән җибәрелә. Бу абзацта күрсәтелгән документлар шифр ярдәмендә яисә эчтәлек белән танышу өчен лицензияле яки башка килешү төзеп сатып алына торган өстәмә программалар таләп ителә торган башка чаралар ярдәмендә сакланган булырга тиеш түгел. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-12.»;

5.3 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1 – 5.3 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларны теркәмәү (барысын да теркәмәү);

гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 4.1 – 4.3 пунктларында күрсәтелгән затлар категориясенә туры килмәве.;

Конкурста катнашу өчен гариза тапшыру срогы бозылу:

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклары, шулай ук мәгълүмат югалырлык яисә аны укымаслык хәлгә китерерлек җитешсезлекләре булган эшләр тәкъдим итү;

гариза бирүченең «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусы булу (авторлар коллективы яисә журналистлар коллективы әгъзасы (лары) «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия булган очракта, чит ил агенты (лары) дип танылган заттан кала, авторлар коллективына яисә журналистлар коллективына катнашу рөхсәт ителә);

тапшырылган конкурс эшенең конкурс һәм (яисә) номинация темасына туры килмәве;

анкетада гамәлдә булмаган сылтама күрсәтү;

Конкурс эшенең Россия Федерациясендә тыелган интернет ресурсларда дөнья күрүе.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү датасы турында мәгълүмат Оештыручы сайтында Конкурс йомгакларын хәбәр иткәндә бирелә.»;

7.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.13. Призлы урын бирелгән конкурс эше журналистлар коллективы яки блогерлар коллективы тарафыннан булдырылган очракта, әлеге призлы урын өчен

билгеләнгән акчалата премиягә бүлеп бирелгән акчалар бу коллектив әгъзалары тапшырган килешү нигезендә Оештыручы тарафыннан алар арасында бүленә.»;

8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Урын | Сумма |
|---|---|---|---|
| 1 | «Социаль челтәрләрдә урнаштыру өчен наркотикларга каршы һәм/яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы видеоролик» | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 20,0 мең сум |
| | | 3 урын | 10,0 мең сум |
| 2 | «Социаль челтәрләр өчен наркотикларга каршы иң яхшы мем һәм /яисә график сурәтләр (рәсемнәр) сериясе» | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 20,0 мең сум |
| | | 3 урын | 10,0 мең сум |
| 3 | «Сәламәт яшәү рәвеше турында иң яхшы текст/ шигырь/җыр» | 1 урын | 40,0 мең сум |
| 4 | «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинация | 2 урын | 25,0 мең сум |
| | | 3 урын | 15,0 мең сум»; |

8.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
8.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8.5. Физик затларга акчалата премияләр (салымы тотылып), җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Оештыручыга җибәрелгән хатта күрсәтелгән банк счетларына акчалар күчерү юлы белән түләнә, яисә Конкурска йомгак ясау турындагы беркетмәгә кул куелган көннән алып 30 көн эчендә Агентлыкның финанс бүлегендә акчалата тапшырыла.

9.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста катнашучылар арасында Конкурста катнашуга рөхсәт ителгәннән соң «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә чит ил агенты дип танылган зат булган авторлар коллективы яисә журналистлар коллективы булса, бу коллектив Конкурс нәтиҗәләре буенча диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.».

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәламәт яшәү рәвешен
пропагандалауга юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын үткәрү
турында

нигезләмәгә
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (Ф.И.Ат. ис.*) | |
| Номинация исеме | |
| Конкурска тәкъдим ителгән эшнең исеме | |
| Аннотация | |
| Конкурс эше урнаштырылган саклау ресурсына сылтама | |
| Адрес | |
| Телефон | |
| Электрон почта | |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары (банк исеме, ИНН һәм КПП, БИК, исәп-хисап счеты номеры | |
| ИНН | |
| СНИЛС | |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсына тәкъдим ителгән конкурс материалларында өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын боза торган материаллар юк;

«Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусым юк;

авторлар коллективы составында «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия затлар юк**.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

** Гариза авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта күрсәтелә

Дата _________________

Имза ______________________ ______________________________»

(фамилия)

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;
3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;
4 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;
5 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев